«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

**ПАЛАТА ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»

**ҖИР һӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ ПАЛАТАСЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

**«28»____07____2023 ел** **№854**

Чистай муниципаль районы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
палатасының 2021 елның 29 сентябрендәге
1099 номерлы күрсәтмәсе белән расланган
муниципаль милектәге җир кишәрлеген
сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага,
даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга,
түләүсез файдалануга бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
административ регламентына
үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, Чистай шәһәр прокуратурасының 2023 елның 24 июлендәге 02-08-02-2023 номерлы протестын караганнан соң

1. Чистай муниципаль районы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасының 2021 елның 29 сентябрендәге 1099 номерлы күрсәтмәсе белән расланган муниципаль милектәге җир кишәрлеген сатулар үткәрмичә, милеккә, арендага, даими (чикләнмәгән вакытка) файдалануга, түләүсез файдалануга бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 2.4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы 20 көн тәшкил итә.

Җир кишәрлеген арендалау килешүенә үзгәрешләр кертелгән яки өзелгән очракта – 9 эш көне.

Җир кишәрлеген алдан килештерү турында Карар кабул ителгәндә – 9 эш көне.

Палата карамагында җир участогының территориядән файдалануның махсус шартлары булган зоналарда булуы турында мәгълүмат булган очракта - 22 көн.

Җир участогын алдан килештерү турында гаризаны карау срогын озайту хакында вәкаләтле орган мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итә.

Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 статьясында каралган тәртиптә җир кишәрлеге бирү турында хәбәрнамәне бастырып чыгару кирәк булган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүнең максималь срогы 50 көн тәшкил итә.».

- 2.8.2.1. пунктындагы 13 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«13) әлеге Кодексның 39.18 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә шәхси торак төзелеше, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару,

гражданнарның үз ихтыяҗлары өчен бакчачылык алып баруы яки крестьян (фермер) хуҗалыгы тарафыннан аның эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен җир участогы бирү турында хәбәр бастырылган һәм урнаштырылган;».

2. 2023 елда җир кишәрлеген алдан килештерү буенча бирү муниципаль хезмәт күрсәтү срогы РФ Хөкүмәтенең «2022 һәм 2023 елларда Россия Федерациясендә җир мөнәсәбәтләрен җайга салу үзенчәлекләре турында»гы 2022 елның 09 апрелендәге 629 номерлы карары нигезендә билгеләнә дип билгеләргә.

3. Әлеге күрсәтмәне Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырырга һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында www.chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче вазыйфаларын
башкаручы Р.Р. Шакиров